Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы
Богородский авыл җирлеге башкарма комитеты

**КАРАРЫ**

29 гыйнвар, 2021 ел № 2

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының Богородский авыл җирлеге территориясендә гражданнарның мөрәҗәгатен карау буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Богородский авыл җирлеге башкарма комитетының 2016 елның 9 апрелендәге 8 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Богородский авыл җирлеге территориясендә гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең Административ регламентын федераль законнарга туры китерү максатларында Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Богородский авыл җирлеге башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының Богородский авыл җирлеге территориясендә гражданнарның мөрәҗәгатен карау буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең Административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 3.13.3 пунктында «министрга (министр урынбасарына)» сүзләрен «башкарма комитет җитәкчесенә (ул булмаганда - аны алмаштыручы затка)» алмаштырырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Богородский авыл җирлеге башлыгы М.Н. Бикбов